| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2019 Зур Тигәнәле авылы № 127

**“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турындагы” 12.04.2013 № 62/3 лы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, 17.08.2019 елгы гавами тыңлаулар (рекомендацияләр) нәтиҗәләрен исәпкә алып,

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы тарафыннан 62/3 номерлы 2013 нче елның 12 нче апрелендә расланган карары белән,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелеше зонасы картасында «СХ1 - авыл хуҗалыгы җирләре зонасы» зонасын (1 нче кушымта) 16:05:040601:158 2 га мәйданлы җир кишәрлеген түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Зур Тигәнәле авыл җирлеге; җирләр категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр; рөхсәт ителгән куллану төре: балыкчылык өчен; шәхси милектә булган зонага«СХ2-авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы»на үзгәртергә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасындагы мәгълүмат стендында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга.


3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. Җ.Әхмәтҗанов**

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Зур Тигәнәле
авыл җирлеге Советының
17.09.2019 № 127 лы
карарына


Схема



Фрагмент карты градостроительного зонирования Большетиганского сельского поселения (графическая часть без изменений)

2нче кушымта
Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Зур Тигәнәле
авыл җирлеге Советының
17.09.2019 ел № 127 лы
карарына

Схема




Фрагмент карты градостроительного зонирования Большетиганского сельского поселения (графическая часть с изменением)